**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РАИФА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**4 март 2019 ел** **№187**

Татарстан Республикасынын Зеленодол муниципаль районы «Раифа авыл жирлеге" җирле үзидарә органнары муниципаль норматив актларында һәм законнарында үзгәрешләргә мониторинг уздыру турында Кагыйдәне раслау турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Раифа авыл жирлеге" җирле үзидарә органнары кабул иткән (бастырып чыгарган) законнарында һәм муниципаль норматив актларында үзгәрешләргә мониторинг уздыру буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Раифа авыл жирлеге" җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Раифа авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Раифа авыл жирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Раифа авыл жирлеге» җирле үзидарә органнары муниципаль норматив актларында һәм законнарында үзгәрешләргә мониторинг уздыру турында Кагыйдәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Раифа авыл жирлеге» җирле үзидарә органнарына:

үзеңнең нормо-иҗат эшчәнлегендә әлеге карарның 1нче пунктында расланган Кагыйдәне нигезләнергә;

әлеге Кагыйдәне үтәү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы зат итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи инструкциясенә ярашлы үзгәрешләр кертергә.

3. Шушы карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодол муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга, һәм шулай ук адреслар буенча Раифа авыл жирлеге мәгълүмати стендларда: Юбилей ур. 13 Бело-Безводное ав., Заречная ур. Садовый пос., Үзәг ур., 1, Раиф пос.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Раифа авыл җирлеге башлыгына йөкләргә

Раифа авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе О.Г. Васильев

Татарстан Республикасы  Раифа авыл жирлеге Советының 2019 елның 4 мартындагы 187нче карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Раифа авыл жирлеге» җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы һәм законнардагы үзгәрешләргә мониторинг уздыру турында Кагыйдә**

**I. Гомуми кагыйдәләр**

1. Татарстан Республикасы  Зеленодольск муниципаль районы “Раифа авыл жирлеге” җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларында һәм законнарда үзгәрешләргә мониторинг (алда – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнарының муниципаль актларны кабул итү (бастыру), үзгәртү яисә көчен югалтуны тану (юкка чыгару) өчен үз вәкаләтләре кысасында мәгълүматларны җыю, туплау, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшне карый.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан  уздырыла.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг уздырганда Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының юридик хезмәте (юридик бүлеге) һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән элемтәгә керә.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг уздыру өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг уздыруның максатлары булып тора:

муниципаль актларны федераль һәм республика законнары белән тәңгәл китерү максатыннан кабул итүдә, үзгәртүдә яисә көчен югалтуда тануны ачыклау ;

муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, төшереп калдыруларны юкка чыгару,  хокукый көйләүдә күчереп алуларны;

җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

муниципаль актларда коррупция фактларын ачыклау;

практикада кулланылмаган (актуальлеген югалткан) яисә таләп ителмәгән муниципаль актларны яисә аларның аерым кагыйдәнамәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокукый яктан куланылыш сыйфатын арттыру;  муниципаль актларны гамәлгә ашыру сыйфатын киметүче факторларны ачыклау ;

җирле үзидарә органнары ярашлы бүлекчәләренең муниципаль актларны үтәвен контрольгә алуда ярдәм итү;

иҗат нормасы процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг үзенә үгәрешләр җыюны, туплауны, анализлауны һәм бәяләүне кертә:

федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка закон актларын;

Россия Федерациясе Президенты указларын, Россия Федерациясе карарларын, федераль башкарма власть  органнарының норматив хокукый актларын, федераль дәрәҗәдәге законлы башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын;

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “Раифа авыл жирлеге» муниципаль берәмлекләре Уставын, муниципаль актларын.

7. Мониторинг уздыруга нигез булып тора:

актларга федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләрне кертү;

хокукый көйләүнең аерым өлкәсендә муниципаль актлар куллануга анализ ясау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

җитешсезлекләр яисә муниципаль актларны камилләштерү кирәклеге турында массакүләм информация чараларында мәгълүмат;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән җәмәгать, фәнни, хокук яклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга уздырган хокукый экспертизасы нәтиҗәләре;

Тиешле тәртиптә муниципаль актларга вәкаләтле затлар әзерләгән коррупциягә каршы экаспертиза нәтиҗәләре;

Җирле үзидарә органнары уздырган конференцияләр, семинарлар, халык тыңлаулары, җәмәгатьчелек тикшерүләре һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг уздыру тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары әлеге Кагыйдәненең 4нче пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән элемтәгә керүдә аларның компетентлыгы мәсьәләләре буенча мониторинг уздыра.

Мониторинг уздыру максатыннан эш төркемнәре төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр уздырылырга, кирәкле мәгълүмат сорап алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектларының тәҗрибәсе өйрәнелергә, эшнең башка формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг анализлау юлы белән алып барыла:

Әлеге Положениенең 6нчы пунктында күрсәтелгән актларны;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларга дәгъва белдерү турындагы эшләр буенча суд актларын (суд практикасын);

прокурор җаваплары актларын.

10. Мониторинг уздыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, һәм шулай ук мониторинг нәтиҗәләре буенча иҗат-норма эше нәтиҗәләрен фиксацияләү максатыннан, җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары карарына ярашлы алып барылган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары кулланыла.

11. Мониторинг алып бару процессын оптимальләштерү максатыннан мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (аларның операторлары белән контрактлар, килешүләр төзүгә бәйле мөмкинлекләр булганда), тәэмин ителә:

«Гарант» информацион системасында законнарны һәм башка норматив хокукый актларны контрольгә кую үзгәрешләре турында мәгълүмат килү;

«Гарант» информацион системасын хокукый көйләүгә ярашлы өлкәләре буенча яңалык тасмасыннан яңалыклар килү;

«Кодекс» информацион компаниясенең «Региональ законнар аналитикасы» автоматлаштырылган информацион системасыннан муниципаль актларның

законнарга тәңгәл килмәвен ачыклау турында мәгълүматлар килү.

Мониторинг алып бару системасын оптимальләштерү максатыннан башка информацион системалар сервислары кулланылырга мөмкин.

12. Мониторинг алып барганда әлеге Положениенең 9нчы пунктында күрсәтелгән анализлаулар белән бергә муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастыруны), үзгәртүне яисә юкка чыгаруны тәэмин итү өчен муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча туплана һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданинның гарантияләнгән хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

муниципаль актлар кабул итү (бастыру) кирәклеген билгеләгән зур юридик көчкә ия булган норматив хокукый актлар булу;

муниципаль актны бастырганда җирле үзидарә органының компетенциясе чикләрен саклау;

муниципаль актта коррупциоген факторлар булу;

җәмәгать мөнәсәбәтләрен хокукый көйләү тулылыгы;

хокук нормалараы коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

муниципаль актны кулланганда аның положениеләренең асылын бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз һәм нигезләнмәгән карарлар, гамәлләр кылу (кылмау);

норматив хокукый актлар куллану практикасы булу;

норматив хокукый актлар кулланунын бер төрле практикасы булмау;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризаларның булуы (саны) һәм эчтәлеге;

муниципаль акт белән көйләнгән мөнәсәбәтләргә һәм аларны кабул итүгә бәйле гариза бирүчеләр таләпләрен кангатьләдерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында суд актларының законлы көченә кергән булуы (саны).

13. Муниципаль актлардагы үзгәрешләргә китергән федераль һәм республика законнарында мониторинг нәтиҗәләре буенча үзгәрешләр ачыкланганда, җирле үзидарә органнары тарафыннан:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану, яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль актларның ярашлы проектлары эшләнә;

муниципаль актларны тагын да зуррак юридик көчкә ия булган актларга тәңгәл китерүгә юнәлтелгән башка чаралар кабул ителә.

14. Муниципаль актларны үзгәртүгә китергән федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертелгәндә мониторинг федераль яисә республика акты басылып чыкканнан алып 30 көн эчендә уздырыла.

Әгәр дә мониторинг уздыруга гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, дәүләт власте органнары, муниципаль берәмлекләр вәкаләтле органнары депутатлары мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокурор актларыннан тыш, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль закон белән билгеләнгән срокларда каралган прокурор мәгълүматы нигез булып торса, мониторинг алар килгән көннән алып 30 көн эчендә ясала. Хезмәт күрсәтелгән очракларда мониторинг уздыру нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать иткән затка хәбәр ителә.

Әгәр дә ерак перспективада гамәлгә кертелгән федераль һәм республика законнары актларында үзгәрешләр ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының норма-иҗат эшчәнлеге планнарына ярашлы корректировка ясау турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен гамәлгә ашыру

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт проектын эшләү һәм муниципаль актын кабул итү федераль һәм (яисә) республика законнарының ярашлы актларына үзгәртүләр кертелгәннән алып ике айдан соңга калмыйча үткәрелә, әлеге Положениенең 14нче пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очрак искәрмә булып тора.

16. Мониторинг уздыруга җаваплы затлар мониторинг нәтиҗәләре турында җирле үзидарә органнары җитәкчеләре каршында ай саен хисап чорыннан соң барган айның 5нче числосында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (белешмә) эчтәлегендә булырга тиеш :

мониторинг уздыру объекты турында мәгълүмат;

мониторинг уздыручылар турында мәгълүмат;

мониторинг уздыру чоры турында мәгълүмат;

мониторинг уздыруга нигез булып торган хокукый көйләү предметына кыскача характеристика.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисапка (белешмә) керергә мөмкин:

ачыкланган хокукый көйләү проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга һәм (яисә) яңаларын кабул итү кирәклеге, муниципаль актларны юкка чыгару турында үзгәрешләрне кертү буенча тәкъдимнәр;

хокукый мөнәсәбәтләрнең ярашлы өлкәсендә хокукый көйләүне камилләштерүгә юнәлтелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәсендә яңадан кабул ителгән муниципаль актлар законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрелә.

Күрсәтелгән регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча анда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма-иҗат процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг уздыруга һәм хокукый иҗат эшчәнлеге өчен җаваплы затларга мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнарын алып баруга кергән хокукый көйләүнең ярашлы өлкәсендә федераль һәм республика законнарына вакытында яраштыру өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылык йөкләнә.

20. Мониторинг нәтиҗәсендә гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән гамәлләр өчен законнарга ярашлы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җавап тота.